| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Красноборского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Красный Бор авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05.09.2022 Красный Бор авылы № 17-1

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге советы карарына үзгәреш кертү хакында (07.02.2020 № 57-2 карары редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына салымнар һәм җыемнар турында үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 15 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге советы нигезендә КАРАР ИТТӘ:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 декабрендәге 41-1 номерлы карарына (2020 елның 07 февралендәге 57-2 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- карарның 2.3 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (https://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет председателе,
Авыл җирлеге башлыгы Е.А.Яковлева

АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ • Совет Красноборского сельского поселения • Красный Бор авыл җирлеге Советы • ИНН 1601002484